**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлеге составына керүче Куаклы авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**
**КАРАР**

20 октября, 2023 ел                                                                                    № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2023 елның 20 октябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«2024 елда яшәү урыны буенча Мәләкәс авыл җирлеге Куаклы авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1000 (бер мең ) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 500 (биш йөз) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

- торак пункт чикләрендә электро - (яктырткычлар һәм электр җиһазлары сатып алу, монтажлау)оештыру;
- торак пункт территориясен төзекләндерүне оештыру (урам исемнәре һәм йорт номерлары белән күрсәткечләр кую, кече архитектура формаларын урнаштыру)

ӘЙЕ                                                            ЮК».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы **16** кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны –10 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы **16** кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенында катнашучы **0** кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлеге Куаклы авылында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип таныргa.

2. «2024 елда яшәү урыны буенча Мәләкәс авыл җирлеге Куаклы авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1000 (бер мең) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 500 (биш йөз) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

- торак пункт чикләрендә электро - (яктырткычлар һәм электр җиһазлары сатып алу, монтажлау)оештыру;

- торак пункт территориясен төзекләндерүне оештыру (урам исемнәре һәм йорт номерлары белән күрсәткечләр кую, кече архитектура формаларын урнаштыру)

мәсәләсе буенча карарны кабул ителгән дип таныргa.

3. Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлеге Куаклы авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл жирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

4. Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлеге Куаклы авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл жирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Мәләкәс авыл җирлеге Башлыгы Ю.П.Васильев